«Буа ветеринария техникумы» студенты, Заһидуллина Зилә Фарил кызы, район күләмендә уздырылган “Татар кызы -2021” бәйгесендә катнашып, җиңүгә лаек булды. Бәйгедә 16 яшьтән алып, 25 яшькә кадәрге кызлар катнашып, үзәренең осталыкларын, туган телебезне белү дәрәҗәсен, гореф-гадәтләребезне күрсәттеләр. Бүгенге көндә туган телен яраткан, аның әдәбияты, мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән кызыксынган укучыларыбыз булуы бик куанычлы.








